КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 гыйнвар г.Казань № 21

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими яшәү урыныннан киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 12 гыйнвар, 3 нче карары белән расланган Даими яшәү урыныннан киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими яшәү урыныннан киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 12 гыйнвар, 3 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 май, 624 нче; 2023 ел, 4 июль, 790 нчы; 2023 ел, 27 ноябрь, 1519 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Даими яшәү урыныннан киткән һәм даими

яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта:

өченче абзацта «гражданнар» сүзеннән соң «2023 елның 1 декабренә кадәр (1 декабрьне кертеп)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән» сүзләрен «әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән Херсон шәһәре территориясендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм башка территориядә яшәү урыны буенча теркәлмәгән» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча гражданнарның теркәлү исәбен гамәлгә ашыручы» сүзләрен «яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәлү исәбен һәм Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны миграция исәбенә алуны гамәлгә ашыручы» сүзләренә алмаштырырга;

2.10 пунктның сигезенче абзацында татар текстында «Гражданнар» сүзеннән соң «2023 елның 29 декабренә кадәр (29 декабрьне кертеп)» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктның беренче абзацында татар текстында «алу өчен» сүзләреннән соң «2024 елның 2 апреленә кадәр (2 апрельне кертеп)» сүзләрен өстәргә;

$3.8^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3.8^1$. Гражданнарның үзләре тапшырган документлары, Министрлык тарафыннан яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәлү исәбен һәм Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны миграция исәбенә алуны гамәлгә ашыручы дәүләт органнарына, Херсон шәһәрендә яисә Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү урыныннан гражданның китү датасы турында Херсон өлкәсенең вәкаләтле органына, дәүләт хакимиятенең башка органнарына җибәрелгән рәсми сорауларга җаваплар нигезендә әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән критерийларга яисә әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве ачыкланган очракта, шулай ук башка Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы тарафыннан югарыда күрсәтелгән туры килмәүләре ачыкланган очракта, Министрлык мондый туры килмәү ачыкланган көннән алып биш эш көне эчендә, социаль түләүне күчергәнгә кадәр, гражданга социаль түләү бирү турында элек кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару турында карар кабул итә.

Министрлык, әлеге туры килмәү ачыкланган очракта, социаль түләүне күчерүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм бу хакта мондый түләүне бирү турындагы карарны элек кабул иткән Россия Федерациясе субъектына хәбәр итә.»;

3.9 пунктта татар текстында «Гражданнар» сүзеннән соң «2023 елның 29 декабренә кадәр (29 декабрьне кертеп)» сүзләрен өстәргә;

4.1 пунктта:

беренче абзацта «гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «күчерү турында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

4.2 пунктта «гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «күчерү турында» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктның өченче абзацында татар текстында «очракта,» сүзеннән соң «2024 елның 2 апреленә кадәр (2 апрельне кертеп)» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин